ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

30 05 2022 г. № 332

**Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 629 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Реклама турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 16 апрелендәге 106-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 629 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.8.2 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

«6) реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең гомуми милке файдаланылган очракта, 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5 өлешендә, 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрне бозу».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны тышкы реклама белән эш бүлеге җитәкчесе Э.И. Мостафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Х. Муллин